ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

7 апрель, 2016 ел № 7/19

Керемнәр хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматларның дөреслеген контрольдә тоту буенча Шәһәр Советы комиссиясе турында

2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Уставы нигезендә
Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Керемнәр хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматларның дөреслеген контрольдә тоту буенча Шәһәр Советы комиссиясен төзергә.
2. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифалар биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматларның дөреслеген контрольдә тоту буенча Шәһәр Советы комиссиясе турында нигезнамәне 1 кушымтага нигезләнеп расларга.
3. Керемнәр хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматларның дөреслеген контрольдә тоту буенча Шәһәр Советы комиссиясе составын 2 кушымтага нигезләнеп расларга.
4. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Шәһәр Советының
7/19 нчы Карарына
1 кушымта
7 апрель, 2016 ел

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифаларны биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматларның дөреслеген контрольдә тоту буенча Шәһәр Советы комиссиясе турында
нигезнамә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифалар биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматларның дөреслеген контрольдә тоту буенча Шәһәр Советы комиссиясе (алга таба – Комиссия) түбәндәге максатлардан төзелгән:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифалар биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифалар биләүче затларның федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәвен тикшерү;

3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифалар биләүче затларның вазифаларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынганлык барлыкка килү турында хәбәрнамәләрен алдан карау.

2. Комиссия Шәһәр Советы тарафыннан Комиссия рәисе, аның урынбасары, Комиссия секретаре һәм әгъзалары составында төзелә.

Комиссия Шәһәр Советы депутатлары арасыннан биш кешедән тиешле чакырылыш Шәһәр Советы вәкаләтләре срогына төзелә.

3. Комиссия эшчәнлеге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм әлеге Нигезнамәгә таянып гамәлгә ашырыла.

## 2. Комиссия вәкаләтләре

4. Комиссия Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифалар биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматларны һәм аларның билгеләнгән

чикләүләрне һәм тыюларны үтәвен 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә тикшерә.

5. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифалар биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын, шулай ук депутатларның федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәвен тикшерү барышында Комиссия хокуклы:

1) муниципаль вазифа биләүче зат белән әңгәмә үткәрергә;

2) муниципаль вазифа биләүче зат тарафыннан тапшырылган материалларны өйрәнергә;

3) муниципаль вазифа биләүче заттан тапшырылган материаллар буенча аңлатмалар алырга;

4) прокуратура органнарына, башка федераль дәүләт органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, федераль дәүләт органнарының территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга аларда булган мәгълүматлар турында: муниципаль вазифа биләүче затның, хатынының һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнаре хакында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында (оператив-эзләү эшчәнлеген башкаруга яки аның нәтиҗәләренә кагылышлы соратулардан тыш); муниципаль вазифа биләүче зат тарафыннан тапшырылган мәгълүматларның федераль законнар нигезендә дөреслеге һәм тулылыгы турында; муниципаль вазифа биләүче затның билгеләнгән чикләүләрне үтәве турында билгеләнгән тәртиптә соратулар җибәрергә;

5) физик затлардан алар ризалыгы белән белешмәләр, мәгълүматлар алырга.

6. Комиссия әгъзалары вазифаларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынганлык барлыкка килү турында хәбәрнамәләрне карау барышында хәбәрнамәләрне җибәргән затлардан аларда бәян ителгән хәлләр буенча билгеләнгән тәртиптә аңлатмалар сорарга һәм дәүләт хакимиятенең федераль органнарына, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга билгеләнгән тәртиптә соратулар җибәрергә хокуклы.

## 3. Комиссия эшен оештыру

7. Комиссия утырышлары кирәк булганда уздырыла. Комиссия утырышын Комиссия рәисе алып бара, ул булмаган очракта, аның күрсәтмәсе буенча – Комиссия рәисе урынбасары. Комиссия утырышында беркетмә төзелә, ул утырышта рәислек итүче тарафыннан имзалана.

8. Комиссия әгъзалары утырышта катнашырга бурычлы. Комиссия утырышында нигезле сәбәп буенча катнаша алмаган очракта, Комиссия

әгъзасы бу турыда Комиссия рәисен алдан кисәтә.

9. Комиссия утырышы Комиссия әгъзаларының билгеләнгән санынnан яртысыннан артыгы катнашса хокуклы.

10. Комиссия карары Комиссия әгъзаларының билгеләнгән саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә. Комиссия әгъзасы аның шәхси үзенә кагылышлы сорау буенча тавыш бирүдә катнашмый.

11. Комиссия әгъзасы үз ирекe белән Комиссия тарафыннан каралучы яки каралачак яшерен мәгълүматны хәбәр итмәү турында йөкләмә кабул итә. Сорауны карау барышында Комиссия тарафыннан алынган мәгълүмат Россия Федерациясе законында каралган тәртиптә генә файдаланылырга мөмкин.

12. Комиссия рәисе Комиссия эшен оештыра, Комиссия утырышларын чакыра һәм үткәрә, Комиссия утырышы беркетмәсенә имза куя.

13. Комиссия рәисе урынбасары Комиссия рәисен ул булмаганда алыштыра, шулай ук Комиссия рәисе күрсәтмәләре нигезендә башка вәкаләтләрне башкара.

14. Комиссия секретаре Комиссия әгъзаларына булачак утырышның көне, вакыты, Комиссия каравына чыгарылган сораулар турында хәбәр итә, Комиссия әгъзаларын Комиссия утырышларында карау өчен кирәкле материаллар белән тәэмин итә, Комиссия утырышы беркетмәсен алып бара.

## 4. Комиссия эшчәнлегене тәэмин итү

15. Муниципаль вазифалар биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрне кабул итүдә, күрсәтелгән белешмәләрне, шулай ук тикшерү материалларын саклауда Хаким (Шәһәр Советы) аппаратының оештыру-аналитик һәм хокукый эшләр идарәсе ярдәм күрсәтә.

15. Комиссия эшчәнлеген оештыру, хокукый, документлар, мәгълүматлар белән һәм башкача тәэмин итү Хаким (Шәһәр Советы) аппараты тарафыннан башкарыла.

16. Керемнәр, чыгымнар хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматлар белән эшләү вазифаи бурычларына кергән һәм әлеге мәгълүматларны таратуда яки аларны Россия Федерациясе законнарында каралмаган максатларда файдалануда гаепле муниципаль хезмәткәрләр Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка ия.

Шәһәр Советының
7/19 нчы Карарына
2 кушымта
7 апрель, 2016 ел

Керемнәр хакында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматларның дөреслеген контрольдә тоту буенча комиссия составы

1. Андреева Флера Ивановна – Комиссия рәисе;

2. Зуйков Сергей Геннадьевич – Комиссия рәисе урынбасары;

3. Аюпова Фирдүсә Фәнәвис кызы – Комиссия секретаре;

4. Кәримов Марат Ришат улы – Комиссия әгъзасы;

5. Тарасов Валентин Петрович – Комиссия әгъзасы.